ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 гыйнвар 2019 ел № 198

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2019 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2018 елның 29 декабрендәге 822/пр санлы Приказы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары белән расланган «2014-2021 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р ӘМ:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2019 елның беренче кварталына 46 170 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ